Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы

КАРАРЫ

2023 елның 11 декабреннән №183

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Шәһәр төзелеше кодексына, Россия Федерациясенең 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Җир кодексына, Россия Федерациясенең 2006 елның 4 декабрендәге 200-ФЗ номерлы Урман кодексына, Россия Федерациясенең 2006 елның 3июнендәге 74-ФЗ номерлы Су кодексына, Россия Федерациясенең 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ (ред. 14.07.2022) "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында", РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 9 июнендәге № 363 Карары «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү турында», «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010елның 25 декабрендәге № 98-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы белән, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге " муниципаль берәмлегенең 2023 елның 11 ноябрендәге җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын тикшерү нәтиҗәләре буенча ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге (https://fgistp.economy.gov.ru/) кушымтада бирелгән Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында дәүләт теркәвенә алганнан соң (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Советының экология, аграр мәсьәләләр, табигый ресурслар һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы урынбасары,

муниципаль район Советы рәисе урынбасары И.Т.Гыйниятов